ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 5 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта «һәм урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга хокуклы» сүзләрен «, шулай ук тиешле үзәкләштерелгән дини оешманың йә үзәкләштерелгән дини оешма вәкаләт биргән җитәкчелек итүче яисә җайга салучы органның ризалыгы белән урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга, өстәмә һөнәри программаларны һәм һөнәри укыту программаларын гамәлгә ашырырга хокуклы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре нигезендә уку-укыту программаларын һәм (яисә) өстәмә һөнәри программаларны, һөнәри укыту программаларын гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары дәүләт йомгаклау аттестациясен яисә йомгаклау аттестациясен узган затларга «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә белем алу турында һәм (яисә) квалификация алу хакында документлар бирәләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 14 июнь
№ 42-ТРЗ